ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2021 Олы Кайбыч ав. № 161

Кайбыч муниципаль районында 2020-2021 еллар ягу сезонын тәмамлау һәм 2021-2022 еллар көзге-кышкы чорда ягу сезонына әзерләнү турында

РФ Хөкүмәтенең «Милекче һәм кулланучыларга күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә, Цельсий буенча 8 градустан югарырак уртача тәүлеклек тышкы һава температурасы артык урнашу сәбәпле һәм ягулык-энергетик комплекс һәм социаль мәдәни көнкүреш объектларын 2021-2022 еллар көзге-кышкы ягу чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1.1. 2020 - 2021 еллар ягу сезонын 2021 елның 30 апреленнән тәмамларга.

1.2. Пар казаннары бинасында, үзәк җылылык пунктларында, җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә һәм эчке инженер системаларында объектларны көзге-кышкы ягу чорына әзерләү чаралары нигезендә ремонтлау һәм профилактика эшләрен башларга.

2. Объектларны 2021 - 2022 елларның көзге-кышкы чорына әзерләүне 2021 елның 15 сентябренә төгәлләргә.

3. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 30 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров